**“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**2018 елның 15 ноябре** **№ 106**

**2014 елның 19 ноябрендәге “Физик затлар милкенә салым турында”гы “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советының 130 нчы номерлы Карарына (2018 елның 4 сенбтябрендәге 94нче номерлы карары редакциясендә) үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексы, “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 36 маддәсе нигезендә, “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ**:

1. 2014 елның 19 ноябрендәге “Физик затларның милкенә салым турында”гы “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Барыш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советының 130нчы номерлы Карарына (2018 елның 4 сенбтябрендәге 94нче номерлы карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә”:

1.1. Карарның 2 пунктының 1 пунктчасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“әлеге пунктның 4 һәм 5 пунктчаларында күрсәтелгән, шул исәптән салым салу объектларында урнашкан салым салу объектларында урнашкан гаражларын һәм машина-урыннарын;

1.2. Карарның 2 пунктының 2 пунктчасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“фатирларны, фатир өлешләрен, бүлмәләрне;”;

1.3. Карарның 2 пунктының 3 пунктчасының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“торак йортларны, торак йортларның бер өлешен;”;

1.4. түбәндәге эчтәлекле 3.1 пункт белән тулыландырырга:

“3.1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Кече Салтык авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәм даими яшәүче 18 яшькәчә өч яки күбрәк балалары булган гражданнар, шулай ук әлеге гражданнарның балалары физик затлар милкенә салым түләүдән азат ителә”

2. Әлеге Карар 2019 елның 1 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән бер айдан да иртәрәк булмаган срокта үз көченә керә.

2017 елның 1 гыйнварыннан физик затлар мөлкәтенә салым исәпләүгә бәйле хокук мөнәсәбәтләренә, 1 пунктчасының икенче абзацындагы, 2 пунктчасының икенче абзацындагы, 2 пунктның 3 пунктчасының икенче абзацындагы (әлеге Карар редакциясендә) нигезләмәләрнең гамәлдә булуы кагыла.

3. Әлеге Карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерү:

- ТР, Кама Тамагы районы, Кече Салтык авылы, Бакый Урманчы урамы, 9, авыл мәдәният йорты;

- ТР, Кама Тамагы районы, Кече Мәрәтхуҗа авылы, Вахитов урамы, 9, авыл мәдәният йортындагы авыл китапханәсе, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

**“Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Башлыгы, “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Кече Салтык авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Советы Рәисе** **А.Г. Җиһаншин**